РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ

Ленин пр,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № _______

Су чыгаруның үзәкләштерелгән системасына һәм чистарту корылмаларына керә торган агып төшүче суларда пычраткыч матдәләр концентрацияләренең рөхсәт ителә торган нормативлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы «Салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агып төшүче сулар составын һәм үзлекләрен тикшереп тору кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы карары нигезендә, әйләнә-тирә мохиткә пычраткыч матдәләр йогынтысын кисәтү максатларында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районындагы предприятиеләрдән һәм оешмалардан үзәкләштерелгән су чыгару системасына һәм «Коммунсервис-Актаныш» ҖЧҖнең чистарту корылмаларына керә торган агып төшүче суларда пычраткыч матдәләр концентрацияләренең рөхсәт ителә торган нормативларын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Күрсәтелгән нормативлар күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга (биологик чистарту корылмаларына шушы абонентлардан керә торган агып төшә торган суларның иң чик мөмкин булган концентрацияләре) кагылмый.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 01 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.
4. «Коммунсервис-Актаныш» ҖЧҖ Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан үзәкләштерелгән су чыгару системасына һәм чистарту корылмаларына җибәрелә торган агып төшүче суларга планлы һәм планнан тыш контрольне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru.урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_____________ №____
1 нче кушымта

Агып төшә торган суларны үзәкләштерелгән су чыгару системасына агызу белән шөгыльләнүче абонентлар өчен агып төшүче сулар составы нормативлары

| Пычраткыч матдәнең исеме | Агып төшә торган суларның табигый пробасында тулаем эчтәлеге һәм (яки) концентрациясе күрсәткеченең рөхсәт ителгән кыйммәте, мг/дм3 |
|---|---|
| БПК5 | 270 |
| ХПК | 267 |
| Үлчәгән матдәләр | 270 |
| Амонний-ион | 11,4 |
| Нитрат-ион | 0,8 |
| Фосфатлар | 0,87 |
| Хлоридлар | 300 |
| Сульфатлар | 144 |
| Майлар | 16,8 |
| АПАВ | 1,2 |
| Тимер | 0,2 |
| Нефть продуктлары | 0,54 |